МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.04.2019 г.Казань № 310

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 27 маеда 5577 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2017 елның 20 июлендәге 477 номерлы боерыгы белән расланган Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктына нигезләнеп, б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 20 июлендәге 477 номерлы боерыгы белән расланган Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның

коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Тәртип эш бирүче тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә (алга таба – граждан хезмәткәрләре) иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте (алга таба – коммерциясез оешма) белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирү процедурасын регламентлый.»;

1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрына

______________________________________

(Ф.И.А.)

______________________________________

(Ф.И.А., били торган вазыйфа һәм структур

______________________________________

бүлекчә, яшәгән урын адресы,

______________________________________

телефон номеры)

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү турында

**ГАРИЗА**

Миңа (кирәклесенең астына сызарга)________________________________________
(иҗтимагый оешманың, торак,

_____________________________________________________________________________белән
торак-төзелеш, гараж кооперативының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең исеме)

______________________________________________________сыйфатында түләүсез нигездә
(бер кеше кулындагы башкарма органның
яисә коллегиаль идарә органының аталышы)
идарә итүдә катнашырга, аларның коллегиаль идарә органы составына керергә рөхсәт бирүне сорыйм.

______________ __________ ______________________________________
(дата) (имза) (фамилия, инициаллар)».

Министр в.б. Р.Ф.Вәлиуллов